Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Иштуган торак пунктында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

24.11.2019 № 1

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының 24.11.2019 ел, 27нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенең Иштуган торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1. 2020 нче елда Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге Иштуган торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Иштуган авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/rus/ishtugan бастырып чыгарырга.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Р.Ш.Галиахметов